БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 03 2021 ел № 119

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартларын раслау турында» 2020 елның 25 маендагы 184 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 18 декаберендәге 1148-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартларын раслау турында» 2020 елның 25 маендагы 184 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар кушымтасының 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Арендага алучы икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре буенча билгеләнә, алар турында 2020 елның 1 апреленә булган мәгълүмат Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында яисә Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында бар.»;

1.2. Карарның кушымтасындагы 3 пунктында:

Беренче абзацта «2020 елның 1 октябренә кадәр» сүзләрен «2021 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. карарның кушымтасындагы «б» пуннктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) кичектереп тору тиешле вакыт өчен аренда түләве күләмендә бирелә;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов